Казан федераль университеты
Филология һәм мәдәниятара бағланышлар институты
Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе

Туган телләр һәм мәдәниятләр өлкәсендә стратегик тикшеренүләр
фәнни белем бирү үзәге

# ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕЛЕМЕН ТИКШЕРҮ ТЕСТЛАРЫ ӨЧЕН КҮРСӘТМӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ЭЧТӘЛЕК ЭЛЕМЕНТЛАРЫ КОДИФИКАТОРЫ

## ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘ

**КАЗАН**
**2024**

Татар телен туган тел буларак өйрәнүчеләр өчен югары дәрәҗәдә белүгә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – тест үтү эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификатор белем эчтәлегенең һәм аңа куелган таләпләрнең системалы бирелешен хасил итә. Бәяләү материаллары биремнәре өйрәнелә торган эчтәлеккә куелган таләпләргә туры китерелеп төзелде. Кодификатор эчтәлегендә югары дәрәҗәгә туры килгән биремнәргә таләпләр чагылыш таба.

Материаллар бирелеше дүрт бүлек кысасында һәм шулар эчендә бирелгән тел, стилистика, тыңланган һәм укылган текстның эчтәлеген аңлау, телдән һәм язма сөйләм материалын үзләштерү буенча белемнәрне тикшерүне күзаллый.

Кодификаторда эчтәлеге төп тематик блоклар эчендәге киңрәк булган тармаклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификаторның әлеге позицияләренең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала. Тикшерү биреме төзеләчәк эчтәлек элементының коды икенче баганада күрсәтелә.

**1 нче бүлек. Тикшереләчәк эчтәлек элементларының исемлеге**

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| **1** | 1.1 | ***Фонетика. Графика. Орфография. Орфоэпия*** |
| | 1.2 | Аваз һәм хәреф. |
| | 1.3 | Татар телендә сузык авазлар |
| | 1.4 | Татар телендә тартык авазлар |
| | 1.5 | Татар телендә фонетик закончалыклар |
| | 1.6 | Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү |
| | 1.7 | Сүзне юлдан-юлга күчерү кагыйдәләре |
| | 1.8 | Интонация |
| | 1.9 | Сүз басымы |
| | 1.10 | Татар телендә сузык авазлар |
| | 1.11 | Татар телендә тартык авазлар |
| | 1.12 | Сингармонизм законы |

| | | |
|---|---|---|
| | 1.13 | о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы һәм әйтелеше |
| | 1.14 | е, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 1.15 | ъ-ь билгеләрнең дөрес язылышы |
| | 1.16 | қ-ғ, к-г авазларының дөрес язылышы һәм әйтелеше |
| | 1.17 | э авазының дөрес язылышы һәм әйтелеше |
| | 1.18 | ия, -ие, -ль гә беткән алынма сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 1.19 | сүз азагындагы [п] һәм [к], [къ] авазларының дөрес язылышы |
| | 1.20 | Ялгызлык исемнәренең дөрес язылышы |
| | 1.21 | Саннарның дөрес язылышы |
| | 1.22 | Кушымчаларның дөрес язылышы |
| | 1.23 | Кисәкчәләрнең дөрес язылышы |
| | 1.24 | Тезмә сүзләрнең дөрес язылыш |
| | 1.25 | Парлы сүзләрнең дөрес язылышы |
| | 1.26 | Кушма сүзләрнең дөрес язылышы |
| **2** | | ***Лексика*** |
| | 2.1 | Сүзнең лексик мәгънәсе |
| | 2.2 | Омонимнар. Антонимнар. Синонимнар |
| | 2.3 | Фразеологик әйтелмәләр |
| | 2.4 | Кулланылышы һәм килеп чыгышы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы |
| | 2.5 | Мәкаль һәм әйтемнәр |
| | 2.6 | Лексик берәмлекләрне тәрҗемә итү үзенчәлекләре |
| **3** | | ***Морфемика һәм сүз ясалышы*** |
| | 3.1 | Сүзнең мәгънәле кисәкләре (морфемалар) |
| | 3.2 | Татар телендә кушымчалар ялгану үзенчәлекләре |
| | 3.3 | Тамырдаш сүзләр |
| | 3.4 | Парлы сүзләр |
| | 3.5 | Кушма сүзләр |
| **4** | | ***Морфология*** |
| | 4.1 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре. Исем сүз төркеме. |
| | 4.2 | Исемнең килеш, тартым, сан белән төрләнеше. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.3 | Сыйфат сүз төркеме. Сыйфат дәрәҗәләре. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.4 | Алмашлык сүз төркеме, аның төркемчәләре. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.5 | Сан сүз төркеме. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.6 | Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.7 | Фигыль заманнары. Кулланылыш үзенчәлекләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 4.8 | Фигыль дәрәҗәләренең кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.9 | Рәвеш сүз төркеме. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 4.10 | Ярдәмче сүз төркемнәре. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| **5** | | ***Синтаксис*** |
| | 5.1 | Сүзтезмә |
| | 5.2 | Җөмлә. Җөмләнең грамматик (предикатив) нигезе. Баш кисәкләр (ия, хәбәр). |
| | 5.3 | Тиңдәш кисәкләр |
| | 5.4 | Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| | 5.5 | Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.6 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.7 | Тулы һәм ким җөмләләр. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.8 | Катлауландырылган гади җөмлә. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.9 | Кушма җөмлә. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.10 | Тезмә кушма җөмлә. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.11 | Иярченле кушма җөмлә. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| | 5.12 | Туры һәм кыек сөйләм. Кулланылыш үзенчәлекләре |
| **6** | | ***Сөйләм үстерү*** |
| | 6.1 | Телдән һәм язма сөйләм |
| | 6.2 | Сүз һәм җөмлә |
| | 6.3 | Текст белән эш |
| | 6.4 | Сүзләрдә авазларның ярашуы |
| | 6.5 | Татар теленең орфоэпик нормалары |
| | 6.6 | Татар сөйләм этикеты |
| | 6.7 | Диалогик һәм монологик сөйләм |
| 7 | ***Пунктуация*** | |
| | 7.1 | Ия белән хәбәр арасында тыныш билгесе |
| | 7.2 | Гади җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 7.3 | Тиңдәш кисәкләр арасында тыныш билгеләре |
| | 7.4 | Эндәш һәм кереш сүзләр, кереш җөмләләр янында тыныш билгеләре |
| | 7.5 | Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре |
| | 7.6 | Кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре |
| | 7.7 | Туры сөйләмдә һәм диалогта тыныш билгеләре |
| | 7.8 | Аныклагычлар янында тыныш билгеләре |
| | 7.9 | Гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре |
| | 7.10 | Нокта кую кагыйдәләре |
| | 7.11 | Сызык кую кагыйдәләре |
| | 7.12 | Ике нокта кую кагыйдәләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 7.13 | Күпнокта кую кагыйдәләре |
| 8 | ***Сөйләм*** | |
| | 8.1 | Сөйләм төре буларак текст. Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге |
| | 8.2 | Стильләр һәм сөйләм төрләре |
| | 8.3 | Тема, максат, адресат һәм аралашу ситуациясенә бәйле рәвештә текстта тел чараларын сайлау |
| | 8.4 | Текстка анализ ясау |
| | 8.5 | Төрле стильдәге һәм сөйләм төрендәге текстлар төзү |
| 9 | ***Тел нормалары*** | |
| | 9.1 | Орфоэпик һәм орфографик нормалар |
| | 9.2 | Лексик нормалар |
| | 9.3 | Грамматик нормалар (морфологик нормалар) |
| | 9.4 | Грамматик нормалар (синтаксик нормалар) |
| 10 | ***Татар сөйләменең матурлыгы*** | |
| | 10.1 | Татар фонетикасының тәэсирлелек чаралары |
| | 10.2 | Сүз ясалышының тәэсирлелек чаралары |
| | 10.3 | Лексика һәм фразеологиянең тәэсирлелек чаралары |
| | 10.4 | Грамматиканың тәэсирлелек чаралары |

**2 нче бүлек. Тикшерелә торган дәрәҗәгә куелган таләпләр исемлеге**

Тәкъдим ителгән биремнәр җыелмасы телне камил белү дәрәҗәсенә туры килә торган белем һәм күнекмәләрне тикшерүгә юнәлдерелгән. Биремнәр дүрт төрле сөйләм эшчәнлеге: тыңлап аңлау, укып аңлау, язма сөйләм, телдән сөйләм биремнәре кысасында бирелә. Биремнәр, беренче чиратта, телне гамәлдә куллана белү мөмкинлекләрен тикшерүгә йөз тора.

| Таләп коды | Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге |
|---|---|
| 1 | Сөйләмне татар әдәби теленең әйтелеш (орфоэпик) нормалары ягыннан бәяли белү |
| 2 | Сөйләмне татар әдәби теленең лексик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 3 | Сөйләмне татар әдәби теленең морфологик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 4 | Сөйләмне татар әдәби теленең синтаксик нормалары ягыннан бәяли белү |
| 5 | Язмача һәм телдән белдерелгән фикерне тел материалының кулланылышы ягыннан, таләп ителгән коммуникатив бурычларга ирешә алуга ярдәм итә алуы ягыннан бәяли белү |

| **Таләп коды** | **Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге** |
|---|---|
| 6 | Грамматик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү |
| 7 | Лексик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү |
| 8 | Фонетика, лексика, сүз ясалышы, морфология, синтаксис буенча алган белемнәрен телнең орфографик һәм орфоэпик нормаларына яраклаштырып куллана белү |
| 9 | Тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү |
| 10 | Язма һәм телдән сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү |
| 11 | Сөйләм стильләрен билгели белү |
| 12 | Сүз ясалышы ысулларын билгели белү |
| 13 | Текстның эчтәлеге турында кыскача төгәл мәгълүмат бирә белү |
| 14 | Башлангыч текстның эчтәлеген аңлый һәм аңлатып бирә белү |
| 15 | Башлангыч текстка нигезләп, үз фикереңне эзлекле белдерә белү |
| 16 | Үз фикереңне эзлекле, бәйләнешле белдерә алу |
| 17 | Сөйләмдә телнең лексик байлыгыннан, төрле грамматик конструкцияләрдән урынлы куллана белү |
| 18 | Язма һәм телдән сөйләмне әдәби телнең орфографик, грамматик һәм пунктуацион нормалары нигезендә төзи белү |